# Тукай турында олуг шәхесләр

## ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНЕҢ КОЯШЫ



*Татарстаныбыз һәм барлык күпмилләтле Россиянең мәдәни тормышындагы күренекле вакыйга - бөек татар шагыйре Габдулла Тукай туугa 120 ел тулу уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм.*

*Барлык төрки һәм шәрекъ дөньясындагы татарлар өчен Тукайның никадәр кадерле булуын әйтеп бирерлек сүзләр юктыр, мөгаен. Аның шигърияте́ндә халкыбызның җаны-рухы чагыла, ә милләт рухы, мәгълүм булганча, беркайчан да үлми һәм бизмәннәрдә үлчәнм. Димәк, Габдулла Тукайның да иҗаты үлемсез һәм иксез-чиксез, ул татар мәдәниятенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән аерылгысыз.*

*Габдулла Тукайның гомере кыска булса да, иҗат ялкынында дөрләп торды, ул үзеннән соң күпкырлы шигъри һәм публицистик мирас калдырды. Тукай кешеләр йөрәгендәге иң нечкә кылларны тибрәткән лирик та, җәмгыятьнең бозык чирләрен рәхимсез камчылаган әче сатирик та, заманның иң мөһим социаль-сәяси күренешләрен ачып салган публицист та булды. Әдәбиятның халык бәхете һәм иреге өчен көрәш юлындагы әһәмиятен аңлап, ул реалистик милли шигърияткә нигез салды һәм күп кенә күренекле татар әдипләре, шагыйрьләре, композиторлары аны үз әсәрләрендә дәвам иттеләр һәм үстерделәр.*

*Рус әдәбияты классиклары А. С. Пушкинны һәм М. Ю. Лермонтовны үзенең остазлары дип санап, Тукай, халыкларны берләштереп торган бетмәс-төкәнмәс рухи кыйммәтләрне шигъри тел ярдәмендә татарларга да җиткерә алды. Аның: "Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл; бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл)",-дигән мәгълүм юллары татар һәм рус халыклары күпгасырлык дуслыгының шигъри манифестына әверелде.*

*Һәр эпоха бөек әдипләрнең яңа сыйфатларын ача, алар иҗатында үзләренә якын яңгыраш таба, Тукайның беренче әсәрләре басылып чыкканнан сон узган йөз елдан күбрәк вакыт эчендә, аның шигърияте татар һәм Россиянеке генә түгел, бөтендөнья мәдәнияте байлыгына әйләнде. Шагыйрьнең әсәрләре бик күп телләргә тәрҗемә ителде, җыентыклары һәм аның турындагы китаплар йөзләрчә тапкыр басылды. Чын шигърият өчен бернинди чикләр юк. Ул нурларын һәркемгә һәм һәр тарафка юмарт сипкән кояш күк.*

*Танылган татар шагыйре Илдар Юзеевның мондый юллары бар:*

Уртак Ватан тарихында эзле иттең син безне,
Мәңге-мәңге тап кунмаслык көзгә иттең син безне.
Сәнгатебез күкләрендә - Кояшыбыз, Аебыз,
Бар җиһанга күренерлек кадерле Тукаебыз!

*Чыннан да, Габдулла Тукай - татар шигъриятенең илебез-җиребез күгенә бер калыккан һәм һичкайчан батмас кояшы ул.*

**М.Ш. Шәймиев,**

Татарстан Республикасы Президенты

***

*Тукай миңа бик иртә кергән. Ана сөте белән. Халык моңнарын тоя башлагач та. Татар халкы бар җирдә Тукай булган. Кайчан дигән сорауга халык сулышы белән дип кенә җавап бирә алам. Шулай булмаса, язарга мин "Пар ат"тан тотынмас идем. Миннән аның беркайчан да чыкканы да юк. Хәтта Дугада да... Сугышла да мине аннан биздерә алмады. Нигә ул миннән чыкмый? Аңлатуы читен. Татарда Тукай туганы өчен куанам. Рухымның Тукай белән очрашуына куанам. Олыгайган саен, күңелгә бер курку урнаша бара. Мин аннан бик авыр аерылырмын шикелле.*

*"Шагыйрь кем?" дигән сорауга җавапны җитмеш өч яшемә җиткәндә Тукайдан таптым. Шагыйрьлекне шагыйрь үзе яшәгән җәмгыятькә керткән рухи көченең микъдары белән үлчәнгәнлеген Тукайны укып аңладым. "Бетте көч, сынды кылыч,—шул булды эш" менә кайчан әйтелә икән. Тукай миндә үзенең милли рухы белән яши. Шул яздыра, шул эчке энергиягә әйләнде. Яшь чакта алга-артка карамый ярыша-ярыша чапкан киләчәк шагыйрьләре дә, минем шикелле картая төшкәч, әлеге сорауга җавапны барыбер Тукайдан эзләячәкләр. "Шагыйрь кем?" Такташ, Туфан, Җәлил дип килерләр дә Тукайда тукталырлар. Шуңа бик нык инандым. Ә шагыйрьгә җавап табарга кирәк икән. Кыскасы, икенче заманда яшәсәм дә, дөньяга ике катлы тәрәзә аша карап яшәдем — Тукай аша. Бөтенесен теоретик нигезли алсам, мин шагыйрь дә булмас идем. Тукай борчу. Тукайдан аерыласым килми...*

**С и б г а т Хәким,**
Татарстанның халык шагыйре

***

*Татар әдәбиятының бәхете булып, дөнья әдәбиятының шатлыгы булып 1886 елны бу фани дөньяга Габдулла Тукай килде. Үз милләтенең гасырларга сузылган газапларыннан һәм өметләреннән, моңнарыннан һәм ырымнарыннан, кан катыш туфракта, изге җирлектә яралды ул. Язмыш аңа бер генә чеметем, бер генә мизгел гомер бирде. Шул ара эчендә ул Россиядә үзен дә, сүзен дә үлемсез итте. Алай гына да түгел, аның исеме һәм даны ил чикләрен узып чыкты. Көнбатыштагы караимнардан алып көнчыгыштагы уйгурларга хәтле барып җитте. Тукайны мин 20 нче гасырда төрки телләрдә иҗат иткән иң бөек шагыйрьләрнең берсе дияр идем. Аның янәшәсенә, ихтимал, Назыйм Хикмәтне генә куеп буладыр.*

*Тукай дигән могҗизаның төп сере нәрсәдә соң? Тукай дигән могҗизаның төп сере шунда, ул үзенең бөек талантын дөнья мәдәниятының казанышлары белән баета алды. Шул талантка, байлыкка баш булып, аны халык тормышының, заманның иң төп, иң олы юлы белән алып китте, алсыз-ялсыз хезмәт иттерде. Аны үз-үзеңә соклану, яки кызык өчен генә сүз уйнату кебек буш, мәгънәсез нәрсәләргә исраф кылмады. Әйтер сүзен ул кешеләр башы өстеннән зәңгәр бушлыкларга карап әйтмәде, ә замандашларының, кан кардәшләренең мөлдерәмә хәсрәт һәм өмет тулы күзләренә туп-туры карап әйтте.*

**М о с т а й К ә р и м ,**
Башкортстанның халык шагыйре.

***

*Минем буын язучыларга Тукай, билгеле, якынрак тора. Без туганда Тукай үзе дә исән булган әле. Өч яшьтән үк без аны белеп, укып үстек. Тукай белән телебез ачылды, дөньяга күзебе зә ачылды. Безнең рухи дөньябызга иң тирән эзне салучы да Тукай булды. Әлбәттә, Тукайның чын мәгънәсендәге кешелекле, халыкчан, демократик иҗаты бүгенге буынны һәм киләчәктәге бик күп буыннарны да рухи тәрбияләп, баетып торачак. Тукай мирасы тирән диңгезне хәтерләтә. Аның төбендә яткан шигъри һәм мәгънәви гәүһәрләрне эзләү, табу һаман да дәвам итәчәк. Бу урында бөек шагыйрьнең бер бик мөһим сыйфатына тукталасым килә. Тукай үз халкының үткәнен бик*

*яхшы белгән һәм исендә тоткан. Тукай үз халкының хәзерге, ягъни үзе яшәгән чордагы тормышны гаять тирән аңлаган. Ниһаять, Тукай үз халкының киләчәге турында даими уйланып, кайгыртып яшәгән. Миңа калса, һәр заманда да чын язучыларга Тукаебызның әнә шул сыйфаты, ягъни үз халкыңның үткәнен белү, бүгенгесен аңлау, киләчәген кайгырту хас булырга тиеш.*

**Әмирхан Еники,**
Татарстанның халык язучысы.

***

*Төрки телләрдә язган язучыларның татар әдәбиятыннан өйрәнмәгәннәре юктыр дип беләм мин. Казахларга, кыргызларга, үзбәкләргә, төрекмәннәргә дә, безгә— Кавказда яшәүче балкарларга, карачай, кумык, азәрбайҗан халыкларына да татар әдәбиятының шифасы, файдасы бик күп булды. Без бүген дә меңъеллык тарихы булган бу әдәбиятка, аның язучыларына зур рәхмәтлебез. Тукай... Тукай иң олуг уртак шагыйрьләребезнең берсе. Безгә аның иҗаты яхшы таныш, Кавказда аны укыйлар, татар телендә дә укыйлар, тәрҗемәдә дә. Ул безнең иң сөекле шагыйребез генә түгел, халыкларны берләштерүче күңел күпере дә.*

**Кайсын Кулиев,**
балкар шагыйре.

***

*Тукай татар халкының гына түгел, ә бәлки барлык төрки халыкларның, шул исәптән үзбәк халкының да сөекле шагыйре булып санала. Тукайның теле дә, Тукай әсәрләренең рухы да безгә гаять тә үз, гаять тә якын, аның сазы моңнары безнең күңелләрдә дә аваздаш яңгыраш таба. ...Тукай һәм башка татар язучыларының иҗаты Үзбәкстаи җиренә демократик фикерләрне, алдынгы карашларны үткәрүче бер күпер булды дисәк, шәт бер дә ялгышмабыз сыман.*

**Абдулла Арипов,**
үзбәк шагыйре.

***

*Г.Тукай, башка төрки халыклар кебек үк, Казан татарларының да тормышы авыр иҗтимагый сәяси вәзгыять хөкем сөргән чорда—XIX гасыр ахырында, XX йөз башында яшәгән. Ул, Казахстанда—Абай, Үзбәкстанда—Чулпан, Әзербайҗанда Сабир һәм Төркиядә Мәхмәт Гакыйф кебек, милләтенең кыен язмышын үз йөрәге аша кичергән шагыйрьләрнең берсе. Яшь Тукайның гомере ятимлектә үткән. Тукай иҗат итүне үзен бу тормыш белән бәйләүче бердәнбер чара итеп санаган һәм аны яшәү рәвешенә әверелдергән.*

*Ни кызганыч, нибары 27 яшендә үлемнең салкын җиле аны бу дөньядан аерып ала. Шулай да, санаулы гына еллар дәвам иткән иҗат гомере эчендә ул озын бер гомергә җитәрлек әсәрләр язып калдырган.*

*Дөньяга карашлары һәм сәяси омтылышлары ни дәрәҗәдә үзгәрәчәге безгә нәмәгълүм булса да, Тукайның иҗат потенциалы нинди зур куәткә ия булуын күзаллау кыен түгел. Бу яшьтә күп кенә шагыйрьләр үзләренең иҗат юлларын әле башлаган гына булса, Тукай халыклар күңеленә нык кереп урнашкан әсәрләр тудырган бөек шагыйрь булып танылырга өлгерә. Әдәби кыйммәте ягыннан аның хәтта тәрҗемәләре дә оригиналга караганда да мөкәммәлрәк. Шушы сыйфаты гына да Тукайның никадәр югары шигъри осталыкка ирешкәнен раслый. Татар әдәбияты тарихчылары үзләре үк язганча, бу җәһәттән Тукай белән һичкем ярыша алмый.*

*...Тукай шәхси тормышын, шәхси кичерешләрен сурәтләгән әсәрләрендә үзен көчлерәк, иркенерәк хис итсә дә, иҗатында ул беренче урынга җәмгыятьне борчыган иҗтимагый проблемаларны куя, милләт алдында килеп баскан кичектермәс мәсьәләләрне күтәрә. Тирә-як мохитне чорнап алган тискәре күренешләрне тәнкыйтьләүне дә ул үзенең намус эше дип саный. Мондый*

*әсәрләрнең кайберләрендә берьяклылык та күзгә ташлана. Вакыт-вакыт ул үзенең иҗат кешесе булуын да онытып, үзе дә сизмәстән башы-аягы белән сәясәткә кереп бата. Ләкин ни генә булмасын, Тукайның шигырьләре ихластан һәм хаклыкны, гаделлекне яклап язылган булуы белән төньяк төркиләр арасында киң тарала, гади халык тарафыннан яратып кабул ителә. Аның күп кенә шигъри юллары мәкаль һәм әйтемнәргә әверелеп телдән-телгә күчеп йөри.*

*Төрек әдәбият сөючеләре арасында Тукай XX йөз башында ук танила башлый. Моны Казанлы Аббас дигән бер әдипнең "Төрек Дәрнәге" мәҗмугасында дөнья күргән "Татар әдәбияты тарихы" дигән язмасы, Фуат Көпрүлүнең "Төрек йорты" журналында басылган "Габдулла Тукаев" исемле мәкаләсе һәм башкалар раслый. Мәгълүм булганча, Советлар берлеге заманында СССР белән Төркия арасында тимер пәрдә корыла, шул сәбәпле бөтен әдәби-мәдәни бәйләнышлар өзелә. Соңгы 20 елда гына Төркиядә төрки халыклар әдәбиятына, шул исәптән Тукае булган татар әдәбиятына карата кызыксыну яңадан уяна башлады һәм бу кызыксыну елдан-ел артыр дип ышанасы килә.*

**Ф а т ы й м а  Ө з к а н ,**
төрек галимәсе.

***

*«Казан казах халкы фикерләрен һәм хисләрен һәрвакыт үзенә тартып торды. Күпләгән казах язучыларының беренче әсәрләре Казанда басылды. Абайның үз туган телендәге беренче китабы Казанда дөнья күрде. Татар әдәбиятын Казахстанда тәрҗемәсез укыдылар. Бу әдәбиятның иҗади йогынтысы — бәхәссез. Казах поэзиясенә нигез салучылары-бызның иҗатына Тукай шигъриятенең нинди зур йогынты ясавын да яхшы беләбез. Алар Тукай шигырьләрен яттан белгәннәр. Безнең күбебез, шул исәптән мин үзем дә, икеләнмичә шуны әйтә алабыз: безнең акыл һәм рухи хәзинәләребездә Тукайның да, татар халкының да өлеше шактый зур».*

**О л ж а с  С ө л ә й м а н о в ,**
казах шагыйре.

***

*«Нинди зур шагыйрь!»— дигән Сергей Есенин Тукай турында...*

*Есенин да, Тукай да — икесе дә зур халык шагыйрьләре, дөньядан алар бик иртә киттеләр, ләкин тугандаш әдәбиятларда, рус һәм татар әдәбиятларында, алар зур эз калдырдылар...»*

**П а в е л  Р а д и м о в ,**
рус язучысы.

***

*«Габдулла Тукай безнең дә шагыйребез. Үзбәк мәктәпләрендә Тукай иҗаты өйрәнелүе, Тукай әсәрләренең үзбәк телендә эзлекле рәвештә басылып чыга килүе, Ташкентның үзәк урамнарыннан берсе Габдулла Ту-каев исеме белән аталуы үзбәк халкының бу зур шагыйрьгә тирән хөрмәтен һәм чын мәхәббәтен раслый, үзбәк һәм татар халыклары арасындагы тарихи дуслыкның матур бер билгесе булып тора».*

**Г а ф у р  Г о л ә м ,**
үзбәкстанның халык шагыйре.

***

*«Мин, әле поэзия өлкәсендә кулыма каләм алмастан элек үк, Тукайның дулкынландыргыч, тирән әсәрләндергеч шигырьләрен күп укыдым...*

*Габдулла Тукайга булган бурычымны үтәү теләге белән, мин аның ике мең юллап шигырен төркмән теленә тәрҗемә иттем...»*

**Берди Кербабаев,**
төркмән язучысы.

***

*«Искиткеч талантка ия булган Габдулла Тукайның шигъри мирасы ул бары тик татар шагыйрьләре милке генә түгел, ул барлык тугандаш республикалар шагыйрьләре өчен дә кадерле һәм газиз...*
*Габдулла Тукай кебек искиткеч талантлар җитештергән татар халкына дан!»*

**Сөләйман Рөстәм,**
әзәрбайҗан халык шагыйре.

***

*«...Тукайның әсәрләре кыргыз халкына бик күптәннән таныш инде... Кыргыз әдәбиятының аксакалы өлкән акыныбыз академик Аалы Токомбаев, күренекле әдипләребез К. Баялинов, У. Абдукаимов, Н. Җантөшев, М. Токобаев, К. Маликов, М. Абдукаримов, Т. Өметалиев һәм башкалар - әле гарәп хәрефләре белән чыккан басмаларыннан Тукай әсәрләрен укып өйрәнгәннәрен сөйлиләр...»*

**Камчы Җунусов,**
кыргыз язучысы.

***

*«Әле 1809 елда ук бөек инглиз шагыйре Гордон Байрон, бик тә чибәр Флоренс Спенсер Смитка багышлап, «Альбомга» дигән шигырен яза. 1836 елда Михаил Юрьевич Лермонтов аны урысчага тәрҗемә итә һәм «Отечественные запис-ки»да бастырып чыгара. Шушы тәрҗемәдән файдаланып, Габдулла Тукай (ул Байрон, Лермонтов иҗатына гашыйк була) 1907 елда, ягъни бөек инглиз шагыйре язганнан соң бер гасыр үткәч, бу шигырьне татарчага тәрҗемә итә.*
*Төрле ил һәм халык шагыйрьләренең мондый дөньякүләм бәйләнеше үзеннән-үзе дә кызыклы, әмма икенче бер нәрсә гаҗәпкә калдыра. Бу юлларны язганда Байронга 21 яшь, тәрҗемә иткәндә Лермонтовка — 22, ә Тукайга 21 яшь була. Шулай итеп, дөньяның өч бөек егете бер гасыр дәвамында, әмма бер үк яшьтә, бертуганнар, игезәкләр кебек, бер дәрәҗәдә фикер йөртә, ярата, газаплана, шигърият утында яна. Бу тәңгәллек очраклы гына булмаган. Ул Габдулла Тукайның татар халкының чын милли шагыйре булуын да, бер үк вакытта Русия поэзиясенең күренекле вәкиле икәнлеген дә, бу исә, үз чиратында, аның дөнья шигърияте вәкиле булуын да тагын бер тапкыр раслый».*

**Сергей Михалков,**
рус шагыйре.

***

*«Габдулла Тукай — якын күршебез һәм туганыбыз татар халкының даны һәм мактанычы, аның иң кыю, иң намуслы һәм иң талантлы улларыннан берсе. Тукай халыкның уйларын, өметләрен, кайгыларын һәм шатлыкларын гаҗәп бер көч белән чагылдыра. Россиядә яшәгән төрле милләт халыклары царизм табаны астында ыңгырашкан ерактагы үткән караңгы заманнарда Тукай, көрәш һәм азатлык факелын күтәреп, Ватанның тормышын һәм кешеләрен тулы тавыш белән сурәтләп җырлаган.*
*Тукай безгә дә — Идел буенда яшәүче барлык халыкларга да кадерле һәм якын. Марилар да, чувашлар да, мордвалар да, удмуртлар да бу зур шагыйрьнең әсәрләрен яратып, чын хөрмәт белән үз итеп укыйлар. Тукайны без, марилар, үзебезнең шагыйребез, дибез. Мари Сергей Чавайн, чуваш Константин Иванов белән бергә Габдулла Тукай безнең мәдәниятебезне баета, дуслык элементләребезне ныгыта, әдәбият ул чикләрне белми бит.*

*Тукай иҗат иткән искиткеч гүзәл поэтик энҗеләр мари укучылары кулында күптән җемелдиләр».*

**Миклап Казаков,**
Мари-Эл халык шагыйре.

***

*«...Тукай үзенең бер шигырендә болай ди:*

*Килде toткынлык, түбәнләнде уемның куллары,*

*Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.*

*...Ул түгел күндем эшеннән, тик ялан кулның эше,*

*Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем.*

*Әнә шундый кырыс башлангыч, Тукай һәм Мәҗит Гафури поэзиясе, Галимҗан Ибраһимовның типографиядә конфискацияләнгән романнары Татарстан Республикасы язучыларына юл әзерләде».*

**Луи Арагон,**
француз язучысы.